Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Прости авыл жирлеге составына керүче Прости торак пунктында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2021 елның 24 октябре № 2

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Прости авыл жирлегенең Прости торак пунктында граждannar җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Түбән Кама муниципаль районының Прости авыл жирлеге Прости торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә 2022 елда үзара салым кертергә. Әлеге сумманың 50% ы күләмендә 2 төркем инвалидлар түли.

2. Алынган акчалар түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдереләчәк:

- мәктәп һәм Кайманов урамнары киселешендә юл полотносын капиталь ремонтлау;

- Прости авылы тукталышыннан 100 мераклыкта юл полотносын ремонтлау (килешү буенча эшләр өчен түләү).

Совет Простинского сельского поселения

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Прости авыл жирлеге башлыгы Д.А. Бәдәртинов